КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 март г.Казань № 146

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 21 октябрь, 904 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына яисә 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 21 октябрь, 904 нче карары белән расланган Социаль эшкуарлар реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) 25 яшькә кадәрге (25 яшьне кертеп) физик затлар тарафыннан төзелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге пунктында билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә 10 календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә заявка бирүчеләрнең заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән заявка бирүчеләргә, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

4.2 пунктның икенче абзацына «, әлеге Тәртипнең 4.1 пунктының егерме дүртенче абзацында каралган очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә;

4.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Конкурс комиссиясенең «Электрон бюджет» системасыннан файдалана алу мөмкинлеге заявкаларны карау беркетмәсе урнаштырылган көннән ачыла.

Конкурс комиссиясе заявкаларны бәяләүнең түбәндәге критерийлары нигезендә «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге бирелгән көннән алып 10 эш көне эчендә заявкаларны карый һәм бәяли:

| Т/с | Бәяләү критерие | Бәяләү критерийларының мәгънәләре | Бәя баллда | Бәяләү критериенең мәгънәләре зурлыгы, % |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Эшчәнлек юнәлеше | Социаль әһәмиятле өлкәдә товарлар әзерләү, җитештерү, хезмәтләр күрсәтү | 100 | 25 |
| | | Товарларны сату, хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару | 30 | |
| 2. | Проектны финанслашу күләме | 50% һәм аннан югары | 100 | 25 |
| | | 40 тан 50% кадәр | 80 | |
| | | 30 дан 40% кадәр | 60 | |
| | | 26 дан 30% кадәр | 30 | |
| | | 25 тән 26% кадәр | 10 | |
| 3. | Проектның уникальлеге - проект булачак бизнесны үсте-рү концепция-сен үз эченә ала | Проект уникаль (булачак бизнесны үстерү концепциясе ачык) | 100 | 25 |
| | | Проект уникаль түгел (булачак бизнесны үстерү концепциясе тулы күләмдә ачылмаган) | 30 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | проект яңа яисә шактый яхшыртылган процесслар, ысуллар, практикалар (яшь эшмәкәр-ләр өчен) эшләүне һәм гамәлгә кертү-не күздә тота | Проект уникаль түгел (проектны үстерү концепциясе юк) | 10 | |
| | Проектның социаль әһә-мияте - проект җәмгыятьтә мөһим социаль үзгәрешләргә юнәлтелгән, анда проект-ның нәтиҗәсе реаль кызык-сыну уята һәм җәмгыять эшчәнлегенә (социаль пред-приятиеләр өчен) йогынты ясый | Проектның социаль әһәмияте ышандырырлык дәлилләнгән (проблеманың актуальлеген рас-лау бар; проектны хәл итүгә юнәлтелгән проблемалар җентек-ләп ачылган, аларны тасвирлау дәлилләнгән һәм конкрет микъдар һәм (яисә) сыйфат күрсәткечләре белән ныгытылган) | 100 | |
| | | Проектның социаль әһәмияте тулы күләмдә дәлилләнмәгән (аларны хәл итү проект йөз тоткан проблеманың йә проблемаларның актуальлеге расланмаган, җентек-ләп ачылмаган, аларның тасвир-ламасы конкрет микъдар һәм (яисә) сыйфат күрсәткечләре белән дәлилләнмәгән яисә ныгытыл-маган) | 30 | |
| | | Проектның социаль әһәмияте дәлилләнмәгән (проектка багыш-ланган проблема җәмгыятьтә кирәкле исәбенә керми яисә проектта нигезләнмәгән) | 10 | |
| 4. | Икътисадый эшчәнлек төр-ләренең гомум-россия класси-фикаторы (ОК 029-2014 КДЕС. Ред. 2) буенча | C бүлеге (эшкәртү производ-стволары) | 100 | 25 |
| | | P (мәгариф), Q (сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтүләр өлкәсендәге эшчәнлек) бүлекләре | 80 | |
| | | R (мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачу оештыру өлкәсендә эшчәнлек), J (мәгълүмат һәм элемтә | 60 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эшчәнлекнең төп төре | өлкәсендәге эшчәнлек) бүлекләре | | |
| | | C (эшкәртү производстволары), P (мәгариф), Q (сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтүләр өлкәсендәге эшчәнлек), R (мәдәният, спорт, ял һәм күңел ачу өлкәсендәге эшчәнлекне оештыру), J (мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендәге эшчәнлек) | 20 | |

Бәяләү критерийларын барлыкка китерүче бәяләү критерийларының әһәмияте күләме 100 процент тәшкил итә.

Йомгаклау билгесен исәпләү өчен һәр критерий буенча балларның бәяләү критериенең мәгънәсе зурлыгына арта. Бер мөрәҗәгать итүченең максималь йомгаклау баллы 100 баллдан арта алмый.

Һәр заявка буенча җыелган баллар санын исәпләү һәр бәяләү критерие буенча бәяләү (балл) күрсәткеченең һәм бәяләүнең тиешле күләме буенча бәяләү критериенең гомуми бәяләүдән әһәмияте буларак билгеләнә.

Грант алу өчен минималь баллар саны - 17,5.

Алынган баллар саны тигезләнгән очракта, заявкаларны ранжировкалау алынган баллар күләмен бәяләү һәм заявкалар керүнең чиратлылыгы йомгаклары буенча киметүгә карап гамәлгә ашырыла.»;

4.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

5.5 пунктта:

өченче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин